**МИНИСТЕРСТВО ЭКОЛОГИИ И ПРИРОДНЫХ РЕСУРСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ ТАБИГАТЬ РЕСУРСЛАРЫ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** Казан **БОЕРЫК**

12.09.2024 №1003-п

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының «Татарстан Республикасы бюджетына Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы тарафыннан администрацияләнә торган түләүләр буенча бурычны түләтүгә өметсез дип тану турында карар кабул итү тәртибен раслау турында» 20.07.2023 ел, №842-п боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы бюджетына Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы тарафыннан администрацияләнә торган түләүләр буенча бурычны түләтүгә өметсез дип тану турында карар кабул итү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының «Татарстан Республикасы бюджетына Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы тарафыннан администрацияләнә торган түләүләр буенча бурычны түләтүгә өметсез дип тану турында карар кабул итү тәртибен раслау турында» 20.07.2023 ел, №842-п боерыгын Россия Федерациясе Бюджет кодексының $47^2$ статьясына туры китерү максатларында боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының «Татарстан Республикасы бюджетына Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы тарафыннан администрацияләнә торган түләүләр буенча бурычны түләтүгә өметсез дип тану турында карар кабул итү тәртибен раслау турында» 20.07.2023 ел, №842-п боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы бюджетына Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы тарафыннан администрацияләнә торган түләүләр буенча бурычны түләтүгә өметсез дип тану турында карар кабул итү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

I бүлегендә:

2 пунктта:

«б» пунктчасының беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«б) «Бөлгенлек (банкротлык) турында» 2002 елның 26 октябрендәге 127-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 127-ФЗ номерлы федераль закон)

нигезендә гражданинның, шәхси эшкуарның банкротлык процедурасын тәмамлау – күрсәтелгән Федераль закон нигезендә аларның түләү йөкләмәсен үтәүдән азат ителгән бюджетка түләүләр буенча бурычлар өлешендә.»;

«в» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«в) банкротлык турындагы эштә кулланыла торган процедураларны үткәрүгә суд чыгымнарын каплау өчен җитәрлек акчалар булмау сәбәпле бурычлыны банкрот дип тану яисә банкротлык турындагы эш буенча эшне туктату турындагы гаризаны суд тарафыннан кире кайтару турында акт кабул итү, бу конкурс производствосын тәмамлау яисә бюджетка түләүләр түләүче гражданинның мөлкәтен сатуны тәмамлау турындагы суд акты белән раслана;»;

«д» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«д) штраф рәвешендә хөкем ителгәннәргә карата амнистия яки ярлыкау турында актлар куллану яки суд тарафыннан карар кабул итү, аңа ярашлы рәвештә бюджет керемнәре администраторы бюджетка түләүләр буенча бурычларны түләтү мөмкинлеген югалтса, шул исәптән аны түләттерүнең билгеләнгән срогы узуга бәйле рәвештә дә, бу амнистия турында акт яки штраф яки суд акты рәвешендә җәзага хөкем ителгәннәргә карата ярлыкау турында акт белән раслана;»;

«е» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«е) «Башкару эше турында» 2007 елның 2 октябрендәге 229-ФЗ номерлы федераль законның (алга таба – 229-ФЗ номерлы федераль закон) 46 статьясындагы 1 өлешенең 3 яисә 4 пунктында каралган нигез буенча башкару документын түләтүчегә кире кайтарганда, әгәр бурыч барлыкка килгән көннән бурычлыга карата бөлгенлек турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән таләпләр күләменнән артмаса, башкаручы суд приставы тарафыннан башкару эшен тәмамлау турында карар чыгару (бөлгенлек) банкротлык турындагы эш буенча производство ачу өчен биш елдан артык вакыт узган булса;».

«ж» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«ж) теркәүгә ала торган орган тарафыннан юридик зат Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан төшереп калдырылганда һәм, 229-ФЗ номерлы федераль законның 46 статьясындагы 1 өлешенең 3 яки 4 пунктында каралган нигез буенча башкару документын түләттерүче затка кайтарып, башкару эшчәнлеген туктату турында суд пристав-башкаручысы тарафыннан элегрәк чыгарылган карар булганда, – оешманың мөлкәте җитәрлек булмау һәм (яки) әлеге оешманы гамәлгә куючылар (катнашучылар) тарафыннан Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән чикләрдә һәм тәртиптә түләү мөмкинлеге булмау сәбәпле бюджетка түләнмәгән түләүләр буенча бурыч өлешендә.

«Юридик затларны һәм шәхси эшкуарларны дәүләт теркәвенә алу турында» 2001 елның 8 августындагы 129-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә теркәүгә ала торган органның юридик затны Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан төшереп калдыру турындагы карары гамәлдә түгел дип танылган очракта, әлеге пунктча нигезендә элегрәк түләттерү өчен ышанычсыз дип танылган бюджет түләүләре буенча бурычы бюджет (бухгалтерия) исәбендә торгызылырга тиеш.»;

түбәндәге эчтәлекле 3 пункт өстәргә:

«3. Тәртипнең 2 пунктында каралган очраклар белән беррәттән, түләнмәгән административ штрафлар, әгәр административ җәза билгеләү турында карар чыгарган судья, орган, вазыйфаи зат тарафыннан Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексында каралган очракларда, административ җәза билгеләү турындагы карар үтәлешен туктату турында карар чыгарылган булса, түләттерү өчен ышанычсыз дип таныла.»;

II бүлектә:

3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Комиссия утырышлары кирәк булганда үткәрелә, әмма елына бер тапкырдан да сирәгрәк түгел. Комиссия карары, әгәр аның утырышында Комиссия әгъзаларының 2/3 өлеше катнашса, хокуклы дип санала.

Комиссия утырышы беркетмә белән рәсмиләштерелә, аңа Комиссия әгъзалары кул куя. Беркетмәне рәсмиләштерү вакыты Комиссия утырышы уздырылган көннән алып биш эш көне тәшкил итә.

Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычны түләтүгә өметсез дип тану мәсьәләсен карау нәтиҗәләре буенча Комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычны түләтүгә өметсез дип танырга – Тәртипнең 2 яисә 3 пунктында күрсәтелгән нигез, шулай ук Тәртипнең 2 һәм 3 пунктларында күрсәтелгән документлар булганда. Бу очракта утырыш уздырылган көннән алып ун эш көне эчендә Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану турында карар проекты әзерләнә;

Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычны түләтүгә өметсез дип танымаска – Тәртипнең 2 яисә 3 пунктында күрсәтелгән нигез һәм Тәртипнең 2 һәм 3 пунктларында күрсәтелгән документлар булмаганда. Әлеге карар Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычны түләтүгә өметсез дип тану мәсьәләсен кабат карауга комачауламый.

Әлеге пунктның бишенче абзацында күрсәтелгән очракта комиссия утырышы беркетмәсендә Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычны түләтүгә өметсез дип тану өчен нигезләр булмау турындагы мәгълүмат чагылдырыла. Беркетмә утырышта рәислек итүче һәм комиссия секретаре тарафыннан имзалана һәм министрга хәбәр итү өчен җибәрелә.»;

4 пунктның унынчы абзацында «рәис» сүзен «утырышта рәислек итүче» сүзләренә алмаштырырга.

2. Хокукый тәэминат бүлегенә шушы боерыкның дәүләт теркәвенә алу өчен Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрелүен тәэмин итәргә.

3. Бу боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Министр А.В. Шадриков